**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА**

423959, Республика Татарстан,
Ютазинский район, деревня Малые Уруссу,
улица Советская, дом 21А.
тел. 85593 4-23-10, факс 85593 4-23-40

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423959, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Кече Урыссу авылы,
Совет урамы, 21А йорты.
эл.адрес Tash.Utz@ tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29 ноября 2023г.** **№ 18**

«Татарстан Республикасы Ютазы районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитеты ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр (хезмәт күрсәтүләр) кабул итү комиссиясе турында һәм товарлар, эшләр, муниципаль контрактлар буенча хезмәт күрсәтүләрне кабул итү комиссиясе составын раслау хакында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының 15.02.2016 ел, № 4 карары белән расланган, Товарларны, эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) кабул итү комиссиясе турында һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитеты ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне кабул итү комиссиясе составын раслау хакында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Кабул итү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Гражданлык кодексына, "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга, башка норматив хокукый актларга, муниципаль контракт шартларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев